| Республика Татарстан<br>Менделеевский муниципальный район<br>Исполнительный комитет<br>Татар Чаллысы авыл җирлеге | Татарстан Республикасы<br>Менделеевск муниципаль районы<br>Татар Чаллысы авылы җирлеге<br>башкарма комитеты |
| --- | --- |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 елның «26»
апреленнән №8

Җир кишәрлеге адреслау объектының адресын үзгәртү турында

«Федераль мәгълүмат адреслы системасы турында һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2013 елның 28 декабрендәге 443-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Адреслар бирү, үзгәртү һәм бетерү кагыйдәләрен раслау турында» 2014 елның 19 ноябрендәге 1221 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт адреслы реестрында урнаштырыла торган адреслар, дәүләт адреслы реестрын алып барганда ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек итү тәртибе турында белешмәләр составы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү һәм гамәлдән чыккан дип санау турында» 2015 елның 22 маендагы 492 номерлы карары, Россия Федерациясе Финанслар Министрлыгының "Планлаштыру структурасы элементлары, урам-юл челтәре элементлары, адреслашу объектлары элементлары, биналар (корылмалар) төрләре, адрес реквизитлары сыйфатында кулланыла торган биналар исемлеген һәм адрес формалаштыручы элементларның кыскартылган атамасы кагыйдәләрен раслау турында" 2015 елның 5 ноябрендәге 171н номерлы приказы, "Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Уставы нигезендә, Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 28 июлендәге 547 номерлы карары белән расланган адресларны бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Кадастр номеры 16:27:0401:1371 булган җир кишәрлеге объекты адресын үзгәртергә: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Менделеевск муниципаль районы, Татар Чаллысы авыл җирлеге, 1371 җир кишәрлеген: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Менделеевск муниципаль районы, Менделеевск шәһәре шәһәр җирлеге, Менделеевск шәһәре, Промзона территориясе, 12 җир кишәрлеге адресына үзгәртергә

2. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Татар Чаллысы авыл җирлеге территориясендә урнашкан җир кишәрлекләре адреслары исемлеген раслау турында» 2019 елның 20 мартындагы 14 номерлы Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Татар Чаллысы авыл җирлеге Башкарма комитеты карарына 1 нче кушымтаның 105 нче юлын гамәлдән чыккан дип санарга
3. Карар аңа кул куйган вакыттан үз көченә керә.

Авыл җирлеге башлыгы Т.П. Кузнецова